ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» 11 2020 Олы Кайбыч ав. № 501

2021 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы балаларын йөртү өчен билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары балаларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын раслау турында

1. 2021 елга:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын, балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын, балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы балаларын йөртү өчен билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары балаларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын раслау турында» 2019 елның 3 декабрендәге 518 номерлы карарын 2021 елның 1 гыйнварыннан гамәлдән чыккан дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Финанс бюджет палатасына:

әлеге карарның 1 пунктында расланган гомуми белем бирү оешмаларын, балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 20 11
501 номерлы карарына
1 нче кушымта

2021 елга гомуми белем бирү оешмаларында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү хакы нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка (елга, сум) | автотранспорт чарасы узган бер километрга ставка, сум |
| КАВЗ | 149595 | 37,79 |
| ПАЗ | 149072 | 37,72 |
| ГАЗ «Газель» | 129791 | 30,61 |
| УАЗ | 129338 | 29,21 |
| FIAT | 132984 | 27,71 |
| Peugeot Boxer | 138182 | 27,36 |
| Ford Transit | 138440 | 30,79 |

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 20 11
501 номерлы карарына
2 нче кушымта

Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын, балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Әлеге Нигезләмә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын, балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт (алга таба - муниципаль хезмәт) күрсәтү бәясен исәпләү механизмын билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм автотранспорт чараларының факттагы узган юлы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең хакы нормативлары ел саен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының фактик узган юлы турындагы мәгълүмат автотранспорт чарасының расланган паспорты кысаларында эшләнгән автотранспорт чарасының хисап елында фактик узышы буларак Татарстан Республикасында аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. $i$ муниципаль берәмлегенә муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

монда:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f_m}$ - $m$ модельле автотранспорт чараларының факттагы узган юлы;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру нормативының бер километрга, бер сумга ставкасы;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда бер автотранспорт чарасына ташуны оештыру бәясе нормативының ставкасы, сум;

$M_m$ - $m$ модельле автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе исеме;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.